РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423586, г. Нижнекамск, пр. Строителей, 12
тел./факс (8555) 41-70-00

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

423586, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
тел./факс (8555) 41-70-00

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

№ 25 2022 елның 14 апреле

Түбән Кама муниципаль районы Советының 2020 елның 27 августындагы 64 номерлы карары белән расланган депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган, әгәр бу мәгълүматларны бозып күрсәтү мөһим булмаса, белешмәләр биргән өчен җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 40 статьясы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының 2020 елның 27 августындагы 64 номерлы карары белән расланган депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган, әгәр бу мәгълүматларны бозып күрсәтү мөһим булмаса, белешмәләр биргән өчен җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3 пунктның 2 абзацында, 4 пунктта, 5 пунктның 2 абзацында, 6 пунктның 1 абзацында, 7 пунктның 1 һәм 3 абзацларында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи заты» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктның 1 абзацында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи затына» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы вазыйфаларын башкаручы,
Башлык урынбасары А.В.Умников